وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!


# Дин вә Мәгыйшәт

№ 11 (128). 16 март 2012 / 23-раббигыль-ахир-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Туйлар котлы булсын, нигез ныклы булсын! ▷2◁



Халкыбызның шигъри юлдашы ▷3◁

«Таян Аллага» исемле III Әдәби конкурс НИГЕЗЛӘМӘСЕ ▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**КОРЪӘН УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ: АКСУБАЙ**

**8 март көнне Аксубай районы мөхтәсибәте балалар өчен Коръән укучылар бәйгесе уздырды. Иске Ибрай авылы мәктәбендә узган әлеге чарада авыл җирлеге башлыклары, мәктәп коллективы һәм ата-аналар катнашты.**

Әлеге бәйге Коръән елына багышланды. Конкурска Аксубай бистәсеннән, Иске Кыязлы, Яңа Ибрай һәм Иске Ибрай авылларыннан 7-17 яшькә кадәрге утыздан артык бала килде. Барлык катнашучыларга да бүләкләр тапшырылды. Тантана мәктәп ашханәсендә оештырылган сый-хөрмәт белән тәмамланды. Аксубай районы мөхтәсибәте бу чараны үткәрергә ярдәм иткән Әсхәт Зиннуровка, Ислам Дәүләтшинга, Рамил Таһировка, Розалия Гыйльмановага, Мәүлемҗан хәзрәт Мәхмүтовка зур рәхмәтләрен белдерә.

**ГАНДБОЛ БУЕНЧА ЯРЫШЛАР УЗДЫ**

**11 март көнне Казан шәһәренең 136 нчы мәктәбендә ТР мөселманнары Диния нәзарәте мөселман яшьләре арасында гандбол буенча ярышлар үткәрде. Әлеге чарада Нурлат, Чистай, Ютазы, Яңа Чишмә, Буа, Актаныш, Менделеевск, Зәй, Питрәч, Мөслим, Сарман, Алабуга, шулай ук Казан шәһәре спортчылары катнашты.**

I урынны - Россия ислам университеты, II урынны - Чистай шәһәре командасы, III урынны Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы исемендәге мәдрәсә командасы яулады.

Җиңүчеләргә дипломнар һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды.

**КОРЪӘН УКУЧЫЛАР БӘЙГЕСЕ: БӨГЕЛМӘ**

**11 март көнне Бөгелмә мөхтәсибәте мәхәллә халкы арасында V Коръән укучылар бәйгесе үткәрде. Әлеге чарада йөзгә якын кеше катнашты, шуларның өчтән бере - өлкән яшьтәгеләр, калганнары яшүсмерләр һәм урта яшьтәгеләр иде.**

Бәйге ахырында барлык катнашучыларга да истәлекле бүләкләр тапшырылды.

- Әлеге бәйгене оештырырга ярдәм иткән барлык иганәчеләргә, шулай ук Урыссудагы "Фәнис" мәдрәсәсенең һәм РИУ каршындагы Коръән-хафизлар әзерләү үзәгенең жюри буларак катнашулары өчен аларга олы рәхмәтләребезне җиткерәбез", - дип билгеләп үтте Бөгелмә мөхтәсибәтенең мәгълүмат һәм дәгъват бүлеге җитәкчесе Хәбир хәзрәт Ханов.

**ЯҢА ҖИТӘКЧЕ**

**14 марттан ТР мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы** "Хәләл" стандартлары комитеты" хосусый учреждение җитәкчесе вазифасына Низамов Марат Ренат улы кереште.

**УТЫРЫШ БУЛАЧАК**

**16 март көнне кичке сәгать алтыда мөфтият бинасында** (Лобачевский урамы, 6) Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясенең чираттагы утырышы узачак. Белешмәләр өчен телефон: 89872639889 (Гөлнара).

***Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды***

# Гыйлем туплау юлында

**Аллаһы Тәгаләдән пәйгамбәребез Мөхәммәткә (сгв) иңгән иң беренче сүз - "Укы!" дигән сүз булган. Шул вакыттан башлап, дин аерым бер кешеләргә генә түгел, ә бар халыкка да ирешә, чөнки пәйгамбәребез (сгв) бу боерыкны барлык кешеләргә дә тарата. Шулай итеп, дин гыйлемен теләгән һәр кеше өйрәнә башлый. Ләкин аны өйрәнү өчен кешенең дөнья һәм чынбарлык төзелеше, әйләнә-тирә турында белем дәрәҗәсе киң булырга тиеш. Коръәни-Кәримнең бер генә аятен аңлар өчен генә дә берничә фән нигезләрен өйрәнергә кирәк. Мәсәлән, аятьтә йолдызлар һәм планеталар турында сүз барган очракта - астрономия, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре турында сүз барганда - социология, элек булган вакыйгалар турында сөйләнгәндә - тарих фәне нигезләрен белү таләп ителә.**

Шуңа да, Коръәндә телгә алынган "укы" сүзе киң мәгънәсендә изге Китапны уку гына түгел, ә гомумән, белем алу турында. Моңа мисал итеп пәйгамбәребез Мөхәммәднең (сгв): "Кытайга барып булса да белем алыгыз", - дигән хәдисен китерергә мөмкин.

"Әмма кичләрдә озын вакыт кыямдә торып, сәҗдә кылып Аллаһка гына коллык кылган мөэмин, ул ахирәт газабыннан куркып Раббысының рәхмәтен өмет итәдер. Шул мөэмин кяфер яки мөшрик монафикъ белән бертигез булырмы? Әлбәттә, һич бертигез булмас! Кешеләргә әйт: "Батыйлны белеп батыйлдан ерак булган, хакны белеп хак тарафында сабит булган хак мөэминнәр, батыйлны да, хакны да белмичә адашып йөргән сукырлар белән бертигез булырлармы? Хакны батыйлдан аеру хакында саф гакыллы кешеләр генә вәгазьләнерләр һәм батыйлдан бизеп хакны кабул итәрләр", - диелә "әз-Зүмәр (Халык төркеме)" сүрәсенең 9 нчы аятендә. Коръәндә галимнәргә бөек дәрәҗә бирелгән. Алар үзләренең белемнәре аркасында башкалардан өстенрәк тора. "Укы!" боерыгы барлык кешеләргә дә кагыла - картларга да, яшьләргә дә, байларга да, фәкыйрьләргә дә. Пәйгамбәребез (сгв): "Бишектән алып ләхеткәчә гыйлем алыгыз", - дип әйткән. Тормышны өйрәнү, кызыксыну, белемгә омтылу - һәр мөселман кешесенең бурычы.

Бүгенге көндә нәтиҗәле эшләүче мәгариф системасы белем алуның нигезе булып тора. Татарстанның мөселман мәгарифе системасы, үз эшчәнлеген яхшырту максатыннан, күп кенә үзгәрешләр кичерде. Яхшы нигез булып бердәм шәригать белеме бирү системасы төзелеше тора. Мөселман мәгарифе өчен бердәм программа булдыру - бу әлеге өлкәдә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте ясаган мөһим адымнарның берсе. Бу программа өч баскычтан тора: мәчет каршындагы курслар; белем бирү вакыты ике елдан биш елга кадәр булган мәдрәсәләр һәм университет.

Уку-укыту эшен расланган бердәм программалар буенча алып бару - бүгенге көндә бик тә әһәмиятле. Укыту процессын унификацияләү (бер стандартка китерү) - булачак дин әһелләре тәрбияләүнең сыйфатын күтәрүдә мөһим адым. Бу мәгариф структурасының барлык дәрәҗәләрендә дә уку-укыту бүлекләренең актив эшләвен һәм шулай ук Диния нәзарәте тарафыннан финанс ярдәме күрсәтелүне таләп итә. Якын арада мәдрәсәләр финанслана башлар, дип уйлыйбыз. Татарстан тарихында моның күзәтелгәне юк иде әле.

**Үзәкләшкән дини оешма - ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# Татарстан мөфтие Төркиягә сәфәр кылды

**ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе Илдус хәзрәт Фәиз Төркиягә сәфәре кысаларында Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура каберләрен зиярат кылды.**

Татарстан мөфтие узган якшәмбедә бер атналык Төркия сәфәрен тәмамлады. Төрек Республикасының Дини эшләр идарәсе җитәкчесе Мәхмәт Гөрмәзнең чакыруы белән килгән Илдус Фәиз, Әнкара белән Истанбулда булды, эшлекле очрашуларда катнашты.

Татарстан делегациясендә шулай ук Татарстан Республикасы Президентының дини берләшмәләр белән хезмәттәшлек идарәсе башлыгы Марат Гатин, Татарстан мөфтиятенең аппарат җитәкчесе Ришат Хәмидуллин, ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Вәлиулла Якупов һәм халыкара бүлек җитәкчесе Хәбибулла Нәфисуллин бар иде.

Узган җомга Истанбулда Илдус хәзрәт Фәиз IRCICA (Ислам тарихын, сәнгатен һәм мәдәниятен өйрәнү үзәге) җитәкчесе Халид Әрән белән очрашты. Очрашуда шулай ук Татарстанның Төркиядәге вәкиле Радик Гыйматдинов та катнашты.

Татарстан мөфтие яңа вазифасында чит илгә беренче рәсми сәфәр кылуын хәбәр итте. Әлеге сәфәрнең максаты - "Төркиянең дин эшләре өлкәсендәге тәҗрибәсен өйрәнү", диде мөфти. Халит Әрән исә IRCICA һәм Татарстанның фән һәм мәдәният өлкәсендә хезмәттәшлеге турында сөйләде. Мөфти И.Фәиз, "Төрек халкы - безнең тугандаш халык, бөек төрки җөмһүрият буларак безгә гел ярдәм кулы суздыгыз", - дип, рәхмәтләрен белдерде.

И.Фәиз Х.Әрән белән Төркия сәфәреннән алган тәэсирләре белән уртаклашты. "Төркиянең илаһият (дин белеме) факультетларында бөек татар галимнәре Галимҗан Баруди, Шиһабетдин Мәрҗәни, Ризаэддин Фәхреддин, Муса Бигиев китапларының асыл нөсхәләре бар. Бездә аларга бик еш мөрәҗәгать итмиләр, ә монда алар киң кулланылышта: ул китаплар буенча фәнни хезмәтләр языла", - дип сөйләде Илдус хәзрәт. Халид Әрән Татарстанның күп кенә төрек университетлары белән хезмәттәшлек итүен җиткерде, ул шулай ук әлеге хезмәттәшлекне тагын да үстерергә кирәклеген белдерде. "Төркиягә Татарстан студентларын җибәрергә кирәк. Мәгариф өлкәсендә хезмәттәшлек бик зур әһәмияткә лаек", - диде IRCICA җитәкчесе.



Соңыннан Татарстан делегациясе Истанбулдагы "Төрки дөнья" мәдәният паркындагы татар һәм башкорт өйләрен карады. Истанбул мэры Кадир Топбаш ярдәме белән ясалган әлеге милли өйләрне атна саен өч меңгә якын кеше зиярат итә. Татар җәмәгатьчелеге монда Сабан туе, Ураза ашлары һ.б. мәдәни чаралар уздыра.

Кунаклар шулай ук Истанбулда урнашкан Габдулла Тукай паркын карады. Якын арада анда бөек шагыйрьнең һәйкәле урнаштырылыр, дип көтелә.

Әюп мәчетендә җомга намазы укып, Мөхәммәд пәйгамбәрнең сәхабәсе Әбу Әюп әл-Әнсаринең төрбәсен зиярат кылгач, Татарстан делегациясе Истанбул мөфтие Рахми Яран белән очрашты.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

# Татарстан мөфтие Төркиягә сәфәр кылды

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Истанбул сәфәренең бер өлеше исә аерым әһәмияткә лаек. Кунаклар Татарстанның Төркиядәге тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Айдар Гашыйгуллин һәм "Идел-Урал төркиләре" җәмгыяте рәисе Гүлтән Ураллы белән бергә Истанбулда җирләнгән танылган татар әдипләренең каберләрен зиярат кылды. ТР мөфтие Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Йосыф Акчура кебек бөек татар зыялылары, дәүләтчелек идеологлары каберләренә дога кылды.

Татарстан делегациясе бер атналык сәфәр кысаларында Әнкара һәм Истанбулда булып, Төркиядәге дини система турында күп мәгълүмат туплады. Кунаклар дини оешмаларда, университетларның илаһият факультетларында, дини китапханәләрдә, Коръән курсларында, өстәмә дини белем бирү үзәкләрендә, төрле мәчетләрдә булды. Делегация бик күп дин белгечләре белән очрашты, тәҗрибә уртаклашты.




Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз сүзләренә караганда, Төркиядә дәүләт белән диннең үзара бәйләнешен өйрәнү бик тә мөһим. Без төрек моделенең бер өлешен, уңай тәҗрибәсен үзләштереп, үзебезнең Татарстанда аны кулланырга телибез, диде ул. Илдус хәзрәт Фәизнең беренче рәсми чит ил сәфәрен нәкъ менә Төркиягә кылуы, мөфтиятнең ышанычлы халыкара хезмәттәш итеп гарәп илләрен түгел, ә кардәш төрек республикасын хуп күрүе турында ишарәли.

***Илдар ГАБИДУЛЛИН***

# Туйлар котлы булсын, нигез ныклы булсын!

## Никах укыту һәм никах мәҗлесе

*(Дәвамы. Башы газетабызның 9 март (№ 10) санында.)*

Никах йоласы байтак кына төбәкләрдә туйдан алда була. Һәм, урынына карап, мәсәлән, Оренбург, Пермь, Самара, Чиләбе якларында һәм Башкортстанның аерым районнарында ул күбесенчә әлеге бәйрәмгә кадәр бер атна яки кайчакта бер-ике ай элегрәк үткәрелә. Ә инде Арча, Саба, Апас, Түбән Кама, Кайбыч, Кукмара һәм башка кайбер районнарда никах төп мәҗлескә чаклы бер-ике көн алдан яисә туй буласы көнне укыла.

Никах күпчелек очракта кыз ягында уза һәм хәзерге вакытта никах мәҗлесендә егет һәм кәләшнең әти-әниләре, якын туганнары гына түгел, ә яшьләр үзләре дә катнаша. Кәләш һәм хатын-кызларның башында бәйләнгән ак яулык, кияү һәм ир-атлар башында түбәтәй була. Мулла шаһитләр алдында яшьләрнең никахлашырга ризалыгын алгач, Коръәндәге "ән-Ниса" һәм "ән-Нур" сүрәләреннән ир белән хатын никахына, шулай ук аларның хокук һәм вазифаларына бәйләнешле аятьләр укый. Ахыр килеп, мулла сорауларына ике яктан да "бирдем"-"алдым" дип җаваплар алынгач, "Амин!" сүзе белән расланып һәм хупланып, никах үз көченә керә.

Никах уку тәмамлангач, никах ашына чират җитә. Алдан ук әзерләнгән табынга йола ашларыннан бал-май, чәкчәк яки бавырсак,



баллы су - ширбәт куела. Шулай ук, ягына карап, итле ризыклардан токмачлы аш, бәлеш тә бирелә. Исерткеч эчемлекләр исә өстәлгә бөтенләй куелмый. Баллы суны, догалар укылып беткәч, изге теләкләр тели-тели, башта килен белән кияүгә эчертәләр. Җае чыкканда, яшьләргә хаждан алып кайтылган зәмзәм суын эчерү гадәте дә бар.

Никахтан соң яшь кияүгә кыз өенә берничә көн куна калырга рөхсәт ителә. Һәм кайбер төбәкләрдә бу йола ("кияү мунчасы"н да бергә кушып) үтәлә дә. Әмма күпчелек очракта егет һәм аның белән килүчеләр никах мәҗлесеннән соң кайтып китәләр. Егет белән кыз, билгеләнгән көнне язылышкач һәм туй үткәч кенә, кавышалар. Казан татарларында һәм Башкортстанның Ык буе районнарында исә никах укыту һәм никах чәе (ашы) уздыру, традицион гадәт буенча, еш кына туй белән бер көнгә туры килә һәм туй әлеге җыйнама вариантта үткәрелгәндә, кагыйдә.буларак, башта хәзерге көнгә яраклаштырылган кияү каршылау йоласы башкарыла. Шуннан соң гына, мулланы алып килеп, никах укыталар һәм җиңелчә генә никах мәҗлесе ясап алалар.

Аннары инде - язылышу тантанасы. Һәм шул кичне шаулап үткән туй мәҗлесеннән соң, яшьләр кыз йортында кавышалар. Йола буенча, кияү мунчасы да кыз ягында була. Яшь кияү шуннан соң кәләше белән берничә көн бабасы йортында кала ала.

## Кияү каршылау, сынау-каршылыклар аша үткәрү

Кияү кешенең кәләше янына килүе яңа горефләр белән үрелгән ике төрле традицион йола белән бәйле: 1) кызны язылышырга алып бару, кичен аның ягында үткәреләчәк туй мәҗлесендә катнашу һәм, бабасы йортында калып, кыз куенына керү өчен; яки 2) кызны язылышырга (кайчакта никах та укытырга) алып китү, үз йортына килен итеп төшерү өчен. Соңгы очракта, димәк, туй да, кияү куенына керү дә егет ягында була. Хәзерге вакытта туй мәҗлесен өченче бер нейтраль урында - кафеда яки ашханәдә уздырылуы да гадәти күренеш. Монысы инде күбрәк шәһәр җире өчен хас.

Яшь кияү сөйгәне янына яки кыз алырга дус-ишләре, туганнары белән машиналарга, яисә, сирәк булса да, җигүле атларга төялеп килә. Капка яки ишек-подъезд төбендә аларны махсус рәвештә тудырылган төрле каршылыклар, берсеннән-берсе хәйләкәррәк итеп корылган тозак-киртәләр каршы ала.

## Язылышу, таныклык алу

Язылышырга, рәсми рәвештә никахлашырга яшьләр кияү каршылау мәҗлесеннән соң яисә никах мәҗлесе үткәч киләләр. Язылышу урыны - шәһәр җирендә ЗАГС, авыл җирендә (хәзерге вакытта) - авыл җирлеге башкарма комитеты. Кайчакта язылышу тантанасын матур итеп бизәлгән, туй плакатлары һәм котлау сүзләре, изге теләкләр язып эленгән мәдәният йортында үткәрәләр.

ГОРЕФ-ГАДӘТ

## Кодаларны каршы алу

Туйга килүче кода-кодагыйларны зурлап, элеккечә җыр белән каршы алу гадәте аерым төбәкләрдә хәзер дә яшәп килә. Бу йола-гадәт бигрәк тә керәшеннәр һәм мишәр татарлары, аларның да өлкәнрәк һәм урта яшьтәге буыннары өчен характерлы.


Әлеге этник төркемнәрдә яшь кияүнең яки кәләшнең әти-әниләре (төп кодалар һәм кодагыйлар) туй буласы якка күбесенчә балалары язылышып кайткач киләләр яисә, әгәр туй мәҗлесе (варианты: өлкәннәр туе) икенче көнне үткәреләсе булса, икенче көнне киләләр. Кыз йортында (кияү ягында) машиналарга яки атларга төялеп килүче кунакларны (алар арасында иярчен яки канат дип йөртелә торган кода-кодачалар да була) капка яки подъезд төбендә каршы алалар. Кайбер якларда туй кодаларын урам башына чыгып, ягъни бераз алга барып каршылау гадәте дә бар.

Каршылаучылар һәм кунаклар җылы итеп күрешәләр. Туйга чакырылганнар әле килеп бетмәгән булса, ишегалдында гәпләшеп, уен-бию оештырып алырга да була. Соңыннан барысы да җыелып, табын әзерләнгән йорт эченә үтәләр.

***Марсель БАКИРОВ, филология фәннәре докторы***

# Халкыбызның шигъри юлдашы

**Татар халкы дөньяның китаби мәдәният белән тирән сугарылган халыкларыннан санала. Аның хәзинәсендә бүгенге көнгә килеп җиткән борынгы китапларның ярым язма, ярым фольклор әсәрләре дә, бик борынгы үз шагыйрьләре иҗат иткән зур-зур дастаннар да, мөселман Көнчыгышының бөек гуманистлары тарафыннан язылган фәлсәфә, медицина, хокук фәне, шигърият кануннары һәм башка өлкәләргә караган китаплар да бар.**



*Рәсем авторы рәссам Айдар ХИСАМОВ*

Алар иске төрки телдә, гарәп һәм фарсы телләрендә язылганнар. Халыкның укымышлылары ул китаплардагы гыйлем яктысын, олы сәнгатькәрләр һәм фикер ияләренең йөрәк җылысын күпсанлы шәкертләр һәм кызыксынучан җәмәгатьчелек арасында таратканнар. Шулар ярдәмендә халыкның үзен ачык карашлы һәм гыйльми фикерле иткәннәр.

Борынгы шигъри әсәрләрне башкаруда безнең халыкка аеруча хас бер үзенчәлек бар: ул - китапны көйләп уку. Моның тамырлары бик тирәнгә китсә кирәк. Фольклорда, мәсәлән, зур-зур эпик әсәрләр көйләп яки речетатив белән башкарылган, ә инде лиро-эпик бәетләр, мөнәҗәтләр көйсез бөтенләй күз алдына да китерелә алмый. Бу традиция шулчаклы тирән һәм көчле урнашкан ки, хәтта читтән кергән шигъри әсәрләр дә махсус көй белән укылган. Мәсәлән, төрекләрдән кергән "Мөхәммәдия" шулай укыла.

Халык репертуарыннан төшми йөргән көйле китаплар арасында аерым бер мөгътәбәр урынны тоткан "Йосыф китабы" бар. Бөек Кол Галинең моннан 779 ел элек язган "Кыйссаи Йосыф" дастанын халык үзенчә шулай атаган. Шагыйрь китабын 1233 елның 12 маенда, һиҗричә тарихның алты йөз утызында, рәҗәп аеның утызында төгәлләгән. Ул - татар халкының болгар дәвереннән бирле кадерләп саклаган җанына иң якын китабы, бөтен тарих буена язмышын уртаклашкан юлдашы.

Кол Галинең шигъри фикерләве тулысынча угыз теле кысаларында бара. Метафоралары һәм гомумән фразеологиясе саф угызча. Әсәрнең телен белгечләр "угыз-кыпчак әдәби теле" дип билгелиләр. Чөнки анда кыпчак теле элементлары да урын алган. Ә шагыйрь үзе мотлак угыз кавеменнән булган. Күренекле тел галиме Әмир Нәҗип әсәрнең Иделнең түбән агымында язылуын әйтә. Сүз Саксин шәһәре турында барырга тиеш. XII гасыр сәяхәтчесе Әбу Хәмид әл-Гарнати Саксин шәһәрендә кырык угыз ыруы яшәгәнлеген, башлыклары болгар әмире булганлыгын һәм шәһәр үзәгендә Җәмигъ мәчете торганлыгын яза. Ә Саксиндә әдәби мохит булган. Сөләйман ибне Даудның "Зөһрәтер-рияз" трактаты Саксиндә язылган.

Фәндә "халык китабы" дигән төшенчә яши. Фикер ияләре аның төп үзенчәлеген "халыкның әхлакый тойгыларын яктыртып ачуда" күргән. "Йосыф китабы" гасырлар дәвамында халкыбызга әнә шундый игелекле хезмәт күрсәткән.

Үзенең күп яклары: каһарманнар яктыртылышы, сюжет корылышы, композициясе һәм халыкта яшәеше белән дастан фольклор эпосына якын торган. Мәсәлән, сюжетның нигез сызыкларыннан берсен тәшкил иткән Йосыф-Зөләйхә мөнәсәбәтенең бирелешен алыйк. Патша кызы Зөләйхә гүзәл Йосыфка төштә күреп гашыйк була. Халык дастаннарына хас сюжет төенләнеше бу. Яки Йосыфның, Мисыр патшасы төшен юрауга ук, патша булып күтәрелүен алыйк. Монысы тылсымлы әкиятләрдәгечә, читен мәсьәлә чишеп, патша булу мотивына корылган. Кол Гали Көнчыгышта киң эшкәртелгән сюжетка бу элементны үзе керткән. Йосыфның, зинданнан чыкканда, үзенең язмышташ бүтән иптәшләрен дә азат кылуны таләп итүе фольклор эпосындагы каһарманның асыл егетләрчә гамәлен хәтерләтә.

Әсәрнең гомуминсани кыйммәте аның үз дәвере өчен гаять үткен яңгыраган һәм сәнгатьчә үтемле гәүдәләнгән үзәк идеясендә. Шагыйрь, дөньяның иң зур байлыгы - ул кеше, дигән фикерне алга сөрә. Моны ул үзенең тышкы матурлыгы белән дә, әхлакый сафлыгы һәм рухани бөтенлеге белән дә камил шәхес булган Йосыф мисалында раслый.

Әсәрдәге гаять бәрәкәтле һәм сәнгатьчә ышандыру көченә ия инсани идеяләрдән кеше бәхетенең төп шарты - әхлакый сафлык, тугрылык дигән фикер дә халкыбыз һәм җәмгыять алга сөргән идеалларга бик якын. Йосыф һәм Зөләйхә мисалында шагыйрь мәхәббәткә һәм гаилә бәхетенә юлның, кеше хакын таптау аша түгел, бары намус һәм сафлык аша үтүен раслый. Егет һәм хатын-кыз каһарманның газаплы аңлашулары вакытында Йосыфның ныклыгы моңа ярдәм итә.

Дастандагы тынычлык пафосы, сугышсыз, тыныч тормышны данлау җөмһүриятебезнең бүгенге эчке һәм тышкы сәясәтенә һәм халкыбызның күпгасырлык хыялларына гаять аваздаш яңгырый.

Поэмада ата белән угылның кайнар мәхәббәте, туганнар ызгышын гаепләү, каһарманның саф, бөтен холкы, Зөләйхәнең гомер буена бер мәхәббәткә тугры булып калуы, көчле характеры, сабырлыгы һәм шулар нәтиҗәсендә һәр өч каһарманның (Йагъкубның, Йосыфның һәм Зөләйхәнең) бәхеткә ирешүе, халыкны гасырлар дәвамында әхлакый тәрбияләп, аның якты өметенә юлдаш булып килгән.

Бүтән төрки әдәбиятларда Йосыф сюжетына язылган әсәрләр саны кырыкка җитә. Мәсәлән, төрек әдәбиятында бу темага унлаган дастан язылган. Татар шигъриятендә "Кыйссаи Йосыф" - мәзкүр сюжетка иҗат ителгән бердәнбер әсәр. Һәм ул төрки Йосыфнамәнең иң беренче әсәре.

Кол Гали поэмасының мондый озын гомерле һәм халкыбыз өчен шушындый газиз булуы аның кешелек җәмгыяте өчен мөһим булган ике зур шартны үтәвенә бәйле. Дастан халыкның дини хисләрен һәм әдәби зәвегын бердәй көч белән гәүдәләндергән. Ул сюжетның буеннан буена ислам диненең мәҗүсилектән пакь һәм өстен булуын раслый.

**Нурмөхәммәт ХИСАМОВ,**
**филология фәннәре докторы,**
**профессор,**
**Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият**
**һәм сәнгать институтының**
**җәмәгатьчелек белән багланышлар**
**буенча директор урынбасары**

**РЕДАКЦИЯДӘН.**

*24 мартта танылган галимебез Нурмөхәммәт Шаһвәли улының олуг юбилее. Без Сезне ихлас күңелдән Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте исеменнән 75 яшьлек юбилеегыз белән котлыйбыз. Аллаһы Тәгалә Сезгә саулык-сәламәтлек, күңел тынычлыгы, иҗат уңышлары насыйп әйләсә иде!*

*Сез Кол Галинең "Кыйссаи Йосыф" әсәрен өйрәнү, аның мирасын халкыбызга җиткерү өлкәсендә ифрат зур хезмәт башкардыгыз. Әдәби тәнкыйть буенча уңышлы эшләп, Г.Тукай, Дәрдмәнд кебек шагыйрьләр иҗатына багышланган мәкаләләр белән чыгыш ясадыгыз.*

*Аллаһы җәнабел Хак Сезгә киләчәктә дә кодрәт-куәт, камил акыл, йомшак фигыль, тулы иман насыйп әйләсен. Сезгә бәйле рәвештә илләребезгә, көннәребезгә, газиз Татарстаныбызга, барча галәм киңлекләренә иминлекләр юлласын!*

# НИГӘ АЛЛАҺ ЯМАНЛЫККА ЮЛ КУЯ?

**Дустым болай диде: "Сез Аллагызны камил, мәрхәмәтле, юмарт дисез, ә ул бит дөньяның бөтен яманлыкларын яраткан: авырулар, картлык, үлем, җир тетрәүләр, янартаулар, микроблар, агу, салкын һәм ни сабыйны, ни картны кызганмый торган яман шешне дә ул бар иткән. Әгәр Алла ярата икән, яхшы икән, нигә Ул яманлыкларны бар иткән?"**

Дустыбыз күтәргән мәсьәлә фәлсәфәдә иң бәхәслеләрдән берсе һәм бу өлкәдә фикерләр күп. Мин аңа болай дидем:

- Алла, чыннан да, Мәрхәмәтле һәм Шәфкатьле. Ул беркайчан да яманлык кылырга боермый, әмма яманлыкны Ул хикмәт - акыл өчен бар иткән. Коръәндә болай диелә: "Чыннан да Алла кабәхәтлек боермый! Үзегез белмәгәнне Аллага сылтарсызмыни? Минем Раббым гаделлек боерды" (7:28)

Алла гаделлек һәм дөреслеккә мәхәббәт белән генә хакимлек кыла һәм Ул яхшылык белән генә канәгать була, хуш күрә.

Нигә соң Алла залимны, катилүтерүчене, карак-угрыны җәзасыз калдыра? Чөнки Алла безнең иркле булуыбызны тели, әгәр бездә яхшы белән яман арасында сайлау мөмкинлеге булмаса, буйсынутәкъвалык һәм гөнаһ кылу арасында сайлый алмасак, ул азатлык мәгънәсез була.

Әлбәттә, Алла сезне барыгызны да тәкъвалы һәм яхшы итә ала, тик моның өчен Ул азатлыгыгызны тартып алырга тиеш була.

Алла кагыйдәләрендә: ачы булса да, азатлык бәхетле коллыктан яхшырак, диелә. Шуңа күрә Алла безне ялгышучан, авыручан һәм өйрәнүчән, сабак алучан иткән - бу исә яманлыкны рөхсәт иткән акылхикмәт. Шуңа күрә Алла болай дигән: "Әгәр Алла кешеләрдән алар ирешкән-казанганнары өчен җавап таләп итсә, түләтсә, Ул җир йөзендә бер кешене дә калдырмас иде, тик Ул билгеле бер вакыткача суза килә" (35:45).

Бу гадел караш шулай ук безгә яхшылыкның асылда нигез икәнлеген, ә яманлыкның - чыгарма икәнлеген ачыклар. Гомеребезнең күп өлешен без сәламәт килеш үткәрәбез, авыру безгә кыска вакыт эчендә генә кагыла. Җир тетрәү дә шуңа охшаш - ул берничә минут кына дәвам итә, миллионнаган еллар яшәгән җир яшәвендә берничә минут. Сугышлар да шулай ук - тыныч тормыш белән яшәгән озак еллар эчендә халыкларның кыска вакытлы бәрелешләре.

Аннан ары бу күренешләрнең һәммәсенең яхшы яклары да бар. Авыру сабырлык тудыра. Газаплар рухны чыныктыралар, түземлелекне, чыдамлыкны ныгыталар. Җир тетрәү - ул җир шарының коточкыч эчке басымы тудырган сулышы. Ул җир тышчасын ярылулардан саклый һәм тауларны, җирне тотучы авыр богаулар кебек үз урынына кайтара. Вулкан - янартау җир асты байлыкларын өскә чыгара, җирне уңдырышлы көл белән каплый. Сугыш хәрби берлекләр булдыра, шикаятьләр һәм килешүләр өчен хәрби трибуналлар булдыра. Сугыш вакытында төрле ачышлар күбрәк ясала: пенициллин, атом, реактив самолётлар - болар барысы да сугыш вакытында уйланып табылган. Елан агуыннан кирәкле дарулар ясыйлар, микроблардан вабага каршы, чәчәк авыруына каршы прививкалар ясыйлар. Әгәр үлем булмаса, без бүген белгән урыннарыбызда булмас идек. Яманлык ул - портретны якыннан караган вакытта барлыкка килгән күләгә кебек, ул бирелә артык нәрсә кебек тоела, ә инде ерактан карасаң, ул күләгәнең кирәклеге генә ачыкланып калмый, рәсемнең матурлыгы да шул күләгәдән торганлыгы ачыклана. Ә авыру? Әгәр авырмасак, сәламәтлекнең кадерен белер идекме? Сәламәтлек ул - башларыбыздагы таҗ кеби. Без аны күрмибез, авырганда гына кадерен белә башлыйбыз. Гариплек булмаса, гүзәллекне аңламас идек! Табигать көчләре үзләрен күрсәтмәсәләр, тормышның гүзәллеген аңламас идек! Шуңа күрә Әбу Хәмит Газәли болай ди: "Чыннан да, дөньядагы даими җитешсезлек аның камиллеге булып тора, ул җәянең иң мөһим нәрсәсе - аның кәкрелегенә охшаш".



Тормыш кыенлыклары кеше табигатенең үзенчәлекләрен ачыклый. Бер шагыйрь әйтүенчә: "Кыенлыклар булмаса, бөтен кешеләр түрә булыр иде, юмартлык ярлыланыр, ә батырлык - үтергеч булыр иде".

Чынлыкта кыенлыклар - безнең өчен сынау, үзенә күрә тикшерү, шуңа карап безнең Алла каршындагы мәгънәбез ачыклана.

"Башларына бәла, кайгы төшкәндә: "Без Алланыкылар һәм Аңа кайтачакбыз",- дип әйткән түземлеләрне сөендер",- диелә Коръәндә.

Чыннан да, фани тормыш ул озын бер кыйссаның бер бүлеге генә, аның артыннан башка фасыллар килә. Ә үлем - бу ахырсыз кыйссаның башы гына. Спектакльгә бәяне бер пәрдәсен генә карап бирмиләр, китапның беренче бите ошамады дип, китапны да тотып атмыйлар. Бәя бирү өчен бу җитми. Нәтиҗә ахырда гына билгеле була. Бездән көлеп, ачысыз, авыртусыз, картлыксыз вә үлемсез тормыш теләп, дустыбыз ни кылмакчы була икән? Ул яшәешнең тулылыгын тели. Тик тормыш тулылыгы Аллада гына. Бердәнбер Алла гына камил. Әгәр анда җитешсезлекләр юк икән, нигә Аңа бердәнбер булмаска ди?

***(Ахыры 4 нче биттә.)***

# Бергәләшеп ярдәм итик!



"Зәкят" хәйрия фондына 6 яшьлек Азалиянең әнисе ярдәм сорап мөрәҗәгать итте. Кызга табиблар куйган диагноз - баш миенең перинаталь патологиясе нәтиҗәсе. Азалия мөстәкыйль рәвештә утыра, тора һәм йөри алмый. Инвалид кызны тернәкләндерү өчен финанс чыгымнар таләп ителә.

"Зәкят" фонды барлык мөселманнарны (һәм шулай ук башка конфессия вәкилләрен дә) әлеге игелекле эштә катнашып, Азалиягә ярдәм итәргә чакыра.

Акчалата ярдәм күрсәтергә теләүчеләр өчен "Зәкят" хәйрия фондының реквизитлары:

***Расчетные счета:***
ИНН/КПП 1655068682 / 165501001
ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012
Р/с: 40703810400020000071
в ОАО "Ак Барс банк" г.Казань, ул.Декабристов, д.1
К/с: 30101810000000000805
БИК: 049205805

Назначение платежа: благотворительность (указать обязательно!)

Адрес: 420111 Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт.

Телефоннар: +7 (843) 236-46-32, 264-60-08.

***Электрон почта: fondzakyat@yandex.ru.***
***Фондның сайты: www.закят.рф.***

# «Таян Аллага» исемле III Әдәби конкурс
# НИГЕЗЛӘМӘСЕ

***ТР Президенты игълан иткән "Татарстанда Тарихи-мәдәни мирас елы" кысаларында үтә торган Коръән елына багышланган «Таян Аллага» исемле III Әдәби конкурс игълан ителә.***

**1. Конкурсның максаты – татар иҗади яшьләре арасында сәләтлеләрне барлау һәм аларны берләштерү.**

**2. Конкурсның бурычлары:**

– сәләтле яшьләргә иҗади үсеш өчен шартлар булдыру;

– татар әдәбиятын һәм мәдәниятен пропагандалау.

**3. Конкурсны оештыручылар:**

– ТР мөселманнары Диния нәзарәте;

– ТР Язучылар берлеге;

– ТР Милли китапханәсе ТР Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты катнашында.

**4. Вакыты һәм үткәрү тәртибе.**

Конкурс өч этапта үтә:

I этап – әсәрләрне җыю (20 февраль 2012 ел – 1 июнь 2012 ел);

II этап – әсәрләрне жюри тарафыннан бәяләү;

III этап – җиңүчеләрне бүләкләү.

**5. Конкурста катнашу шартлары.**

Конкурста Татарстан һәм татарлар яши торган төбәкләрдән теләгән һәр кеше катнаша ала. Конкурска әсәрләр татар телендә электрон вариантта кабул ителә.

Конкурс өч номинациядә үтә: шигърият, чәчмә әсәрләр, драматургия. Аз күләмле әсәрләр (шигырьләр, кыска хикәяләр һ.б.) өчтән ким булмаска тиеш. Әсәрләр белән бергә конкурста катнашучы үзе турында мәгълүмат җибәрергә, үзенең өй адресын һәм телефон номерын күрсәтергә тиеш.

**6. Нәтиҗә ясау һәм бүләкләү.**

Конкурста катнашучыларның әсәрләрен жюри әгъзалары бәяли. Һәр номинациядә I, II, III урыннар һәм Гран-при билгеләнә. Моннан тыш, махсус бүләкләр дә бирелергә мөмкин. Жюри Гран-при һәм призлы урыннарны бирмәү хокукына да ия.

Конкурс нәтиҗәләре буенча «Таян Аллага» исемле әдәби җыентык чыгарыла. Ул конкурска килгән иң яхшы әсәрләрдән туплана.

**7. Жюри составы.**

Жюри оештыру комитеты тарафыннан билгеләнә.

**8. Оештыру комитеты.**

***Оештыру комитетының адресы:*** *Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт. Телефон: +7 (843) 238-35-18.*

***Электрон почта:*** *tayanallaga@yandex.ru.*

# НИГӘ АЛЛАҺ ЯМАНЛЫККА ЮЛ КУЯ?

***(Ахыры. Башы 3 нче биттә.)***

Моның асылы шунда ки: дустыбыз үзе Алла булмыйча канәгать булмаячак, ә бу исә орыну. Безнең доктор дустыбыз тиз генә гаҗәпләнә торганнардан түгел. Ул тырышмыйча һәм кыенлыклар аша узмыйча гына әзергә хәзер җәннәткә ирешмәкче була. Әмма җәннәткә лаек булу өчен ул ниләр эшләде? Әлеге фәннәр докторы бер теләве белән бар итә торган Алла булу өчен кешелек дөньясына нинди хезмәт күрсәтте?

Минем әбием доктордан күпкә акыллырак, ул: "Яхшылык Алладан, ә яманлык үзебездән!" - ди. Бу сүзләр, гади генә булсалар да, барлык проблемаларны хәл итәләр. Алла елгаларны агызган, җилләрне юнәлткән, тик саран капитан гына корабына хәтсез кеше вә мал тутырып, тиешеннән күп йөк алган һәм шул сәбәпле кораб баткан.

Алланың гаебе нидә соң? Нигә ул үз бәласендә Алланы һәм язмышын гаепли? Алла елгаларны бар иткән, йөзү өчен яхшы һава торышы биргән, тик кешенең саранлыгы бу игелекне яманлыкка әверелдерде.

"Яхшылык - Алладан, яманлык - үзебездән" дигән әлеге сүзләр нинди гадел һәм дөрес.

***WWW.MUSULMAN.SU***

# МӘЧЕТЛӘР КАРШЫНДАГЫ ӨЧЬЕЛЛЫК КУРСЛАР ӨЧЕН УКЫТУ ПРОГРАММАСЫ

ЯҢА КИТАП

***Программа ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең уку-укыту бүлеге тарафыннан әзерләнде.***

Әлеге программаның максат-бурычы - мәчетләр каршындагы башлангыч белем бирү курсларында ислам дине нигезләрен сыйфатлы итеп укыту. Кешеләрнең Ислам кушканнарны кабул итеп, мөселман булып формалашуында бу курсларның әһәмияте бик тә зур. Курсларның эшчәнлеген тиешле рәвештә оештыру ислам динен ата-бабаларыбыз алып барган рәвештә дәвам итү эшенә бихисап өлеш кертү булыр иде. Шуның өчен бу курсларны тиешле уку-укыту программалары һәм мөгаллимнәр белән тәэмин итү сорала. Кызганыч, мәчет-мәдрәсәләрдә билгеле бер тәртипкә салынган, барысы да куллана ала торган уку-укыту программалары әлегә кадәр юк иде. Нәшер ителгән берьеллык һәм өчьеллык укыту программалары бу мәсьәләне кардиналь рәвештә тәртипкә салыр, дип өметләнәбез.

Өчьеллык уку-укыту программасы бер еллык программаның дәвамы буларак тәкъдим ителә. Биредә берьеллык программага кергән алты бүлек калдырылды, алар берьеллык программадагы темалар белән тулыландырылды. Аларның сәгатьләр саны да арттырылды. Өчьеллык программаның тагын бер аермасы шунда: биредә гарәп теле бүлеге өстәлде. Ул II һәм III курсларда укытыла, чөнки I курста шәкертләр интенсив рәвештә тәҗвид кагыйдәләрен өйрәнә. Сира дәресенә килгәндә, беренче елны ул пәйгәмбәребезнең (сгв) тормыш юлы буларак бара. Икенче елны ул шул ук рәвештә Ислам тарихына күчә. Өченче елда татар халкында ислам дине гасырлар дәвамында нинди урын алып торганлыгы турында мәгълүмат бирелә һәм күренекле татар галимнәре белән таныштыру дәресләре үткәрелә. Әлеге предметны эзлекле укытуның максаты - тарихи чылбырны өзмичә, аның укучылар тарафыннан үзләштерелүен тәэмин итү. Әлеге фәнне укыту бик тә мөһим, чөнки татар халкы Ислам үсешенә шактый зур йогынты ясаган һәм бу мирасны кире кагу зур мәгънәсезлек булыр иде.

**Әлеге уку-укыту программасы 7 предметтан гыйбарәт; аңа барлыгы 504 сәгать бирелгән. Курсларның уку-укыту программасына түбәндәге фәннәр кертелә:**

1. Исламда әдәп-әхлак.
2. Гакыйдә.
3. Тәҗвид.
4. Фикъһе.
5. Коръән. Коръән аятьләренең тәфсире белән танышу.
6. Сира. Дүрт хәлифә турында кыскача мәгълүмат. Болгар бабаларыбызның ислам динен кабул итүе. Ислам тарихы һәм цивилизациясе. Татар халкы тарихында исламның урыны. Татар зыялылары.
7. Гарәп теле.

# Татарстан мәдрәсәләрендә фән олимпиадаларын үткәрү тәртибе

***Бүгенге көндә Татарстанның мөселман дини белем бирү учреждениеләрендә (мәдрәсәләрдә) ислам дине фәннәре һәм гарәп теле буенча олимпиадалар, Казан мәдрәсәләрен исәпкә алмаганда, үткәрелми диярлек.***

Бөтен Россия дәрәҗәсендәге олимпиада һәр елны (2008 елдан башлап) Россия ислам университеты тарафыннан үткәрелә. Олимпиада илебезнең мөселман дини уку йортларында белем алучы студентларны җыя.

Шуңа бәйле рәвештә, студентларның өлгерешен арттыру һәм аларны фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүгә җәлеп итү максатыннан, Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз Татарстан мәдрәсәләрендә олимпиадаларны түбәндәге тәртиптә үткәрү боерыгы бирелгән 113 номерлы фәрманны имзалады (ул 2012 елның 14 мартыннан гамәлгә керде):

- март аенда мәдрәсәләрнең үзләрендә олимпиадалар үтә;
- апрельдә өч фән (предмет) - гакыйдә (догматика), фикъһе (ислам хокукы) һәм гарәп теле буенча Республика олимпиадасын оештырырга;
- май аенда РИУ оештырган Бөтенроссия олимпиадасын үткәрү эшендә катнашырга.

# Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 17.03.12 | 5:23 | 6:53 | 13:02 | 16:55 | 18:52 | 20:22 |
| Якшәмбе | 18.03.12 | 5:20 | 6:50 | 13:02 | 16:57 | 18:54 | 20:24 |
| Дүшәмбе | 19.03.12 | 5:18 | 6:48 | 13:02 | 16:58 | 18:56 | 20:26 |
| Сишәмбе | 20.03.12 | 5:15 | 6:45 | 13:02 | 16:59 | 18:58 | 20:28 |
| Чәршәмбе | 21.03.12 | 5:12 | 6:42 | 13:02 | 17:01 | 19:00 | 20:30 |
| Пәнҗешәмбе | 22.03.12 | 5:10 | 6:40 | 13:02 | 17:02 | 19:02 | 20:32 |
| Җомга | 23.03.12 | 5:07 | 6:37 | 13:02 | 17:03 | 19:04 | 20:34 |
| Шимбә | 24.03.12 | 5:04 | 6:34 | 13:02 | 17:05 | 19:06 | 20:36 |

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 10 (127) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-527.
**Газета бушлай таратыла.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 15 март көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.
Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллanудан сакланыгыз!**